**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**

**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ТЮЛЯЧИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**

**ТЕЛӘЧЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **с. Тюлячи** **КАРАР**

«26» декабря **2024ел** **№ 170**

Теләче муниципаль районы Башкарма комитетының 2023 елның 18 июлендәге 109 номерлы «Торак бинаны торак булмаган бинага һәм торак булмаган бинаны торак бинага күчерү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясе Торак кодексына һәм «Күчемсез милекне дәүләт теркәве турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» 2023 елның 19 декабрендәге 608-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Торак кодексы нигезендә, Теләче муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Теләче муниципаль районы Башкарма комитетының 2023 елның 18 июлендәге 109 номерлы «Торак бинаны торак булмаган бинага һәм торак булмаган бинаны торак бинага күчерү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» карарына (21.11.2023 № 179, 10.10.2024 № 124 карарлар редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

- күрсәтелгән карар белән расланган Торак бинаны торак булмаган бинага һәм торак булмаган бинаны торак бинага күчерү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына:

А) 3.5.4 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.5.4. Муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсен әзерләү өчен җаваплы вазыйфаи зат:

Регламентның 2.9.2 пунктында күрсәтелгән муниципаль хезмәт күрсәтүдән баш тарту өчен нигезләрне ачыклаганда, ә ведомствоара комиссия карар кабул иткән очракта, ведомствоара комиссия карарын исәпкә алып, торак (торак булмаган) бинаны торак булмаган (торак) бинага күчерүдән баш тарту турында хәбәрнамә проектын әзерли;

Регламентның 2.9.2 пунктында каралган муниципаль хезмәт күрсәтүдән баш тарту өчен нигезләр булмаган очракта, муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документларны карау нәтиҗәләре буенча торак (торак булмаган) бинаны торак булмаган (торак) бинага күчерү турында хәбәрнамә проектын әзерли, кирәк булган очракта, мондый бинаны торак яки торак булмаган бина буларак куллануны тәэмин итү өчен үзгәртеп кору һәм (яки) яңадан планлаштыруны үткәрү турында таләпне кертеп;

торак яисә торак булмаган бина сыйфатында бинаны файдалануны тәэмин итү өчен аны яңадан урнаштыру таләп ителмәгән, һәм (яисә) яңадан планлаштыру, һәм (яисә) башка эшләр таләп ителмәгән очракта, РФ Торак кодексының 23 статьясындагы 5 өлешендә каралган документ торак урынны торак булмаган бинага яисә торак булмаган бинага күчерү турында карар кабул итүне раслый, ул күчемсез мөлкәтнең Бердәм дәүләт реестрына үзгәрешләр кертү өчен нигез булып тора. Бу очракта күрсәтелгән күчерү мондый бинаның билгеләнеше турында Бердәм дәүләт күчемсез мөлкәт реестры белешмәләренә тиешле үзгәрешләр кертелгән көннән тәмамланган дип санала;

әзерләнгән муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсе проектын билгеләнгән тәртиптә электрон документ әйләнеше системасы аша килештерүгә җибәрә.

Административ процедуралар бер эш көне эчендә башкарыла.».

2. Әлеге карарны гамәлдәге законнар нигезендә бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карар гамәлдәге законнар нигезендә үз көченә керә.

Җитәкче И.Х. Хәмидуллин